**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2019 № 1160

2020 елга Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә (башкарыла) торган һәм Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләргә (эшләргә) норматив чыгымнарны раслау турында

«Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда файдаланыла торган музейлар, китапханәләр, мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару кыйммәте нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009елның 21 сентябрендәге 864 номерлы һәм «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә (башкарыла) торган муниципаль хезмәтләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында " 2015 елның 5 сентябрендәге 638 номерлы карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРДЕ:

1. 2020 елга расларга:

-2020 елга Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә норматив чыгымнар;

-2020 елга Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган муниципаль эшләргә норматив чыгымнар;

2. Кама Тамагы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә, мәдәният учреждениеләрен финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына М. Х. Хабибулловага йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин

Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының 30.12.2019 ел 1160 номерлы карары белән расланган

**2020 елга Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| № т/б | Учреждение исеме | Хезмәтнең исеме | Норматив чыгымнар, сумнар | Хезмәт, ел күләменә | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Музейлар | музей предметларын, музей коллекцияләрен күрсәтү | 2153200 | 5973 | берәмлек |
| 2 | Китапханә | Китапханә, библиографик һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү | 14113100 | 323001 | берәмлек |
| 3 | Клуб тибындагы учреждениеләр | Кинофильмнар күрсәтү, клуб формированиеләре һәм үзешчән халык иҗаты формированиеләре эшчәнлеген оештыру | 45400800 | 387446 | берәмлек |

Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының 30.12.2019 ел 1160 номерлы карары белән расланган

**2020 елга Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган муниципаль эшләргә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| № т/б | Учреждение исеме | Хезмәтләрнең исемлеге | Норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Музейлар | тарихи-архитектура комплексының, тарихи мохит һәм ландшафтларның сакланышын һәм бөтенлеген тәэмин итү | 2153200 |
| | | музейларның экспозицияләрен (күргәзмәләрен) булдыру, күргәзмәләр оештыру | |
| | | музей предметларын, музей коллекцияләрен реставрацияләү һәм консервацияләү | |
| | | музей предметларын, музей коллекцияләрен формалаштыру, исәпкә алу, өйрәнү, физик сакланышын һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү | |
| 2 | Китапханә | библиографик эшкәртү документлар һәм каталоглар булдыру | 14113100 |
| | | китапханә фондын (китап һәйкәлләрен дә кертеп) тотрыклыландыру, реставрацияләү һәм консервацияләүне гамәлгә ашыру | |
| | | фондларны цифрлаштыруны да кертеп, китапханә фондларын формалаштыру, исәпкә алу, өйрәнү, физик яктан саклануын һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү | |
| 5 | Клуб тибындагы учреждениеләр | кинофильмнар күрсәтү, клуб формированиеләре һәм үзешчән халык иҗаты формированиеләре эшчәнлеген оештыру | 45400800 |